# КАРАР
## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Төрек-Тәмте торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 7 декабре Төрек-Тәмте авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 7 декабрендә Төрек-Тәмте торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Төрек-Тәмте торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:
- урамнарга вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)түбәндәге урамнар буенча: Центральная, Бауман;
- юлларны кардан чистарту.

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:
Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 62 кеше кертелгән
җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләр саны 43 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:
гражданнар җыенында катнашкан 43 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Төрек-Тәмте торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре- дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Төрек-Тәмте

торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:
кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Интернет челтәрендә Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башлыгы Ф. Р. Мәхмүтов